| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.04.2018 № 281

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты 2017 ел, 13 июнь, 527 нче карарына
үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында” Федераль законының 51маддәсенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 8 май, 28нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3 пунктына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы «Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның җитәкчеләрен (директорлар, балар бакчалары мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турында Якынча нигезләмәне раслау турында” 2014 ел, 10 ноябрь, 6347/14 номерлы боерыгына өстәлмәгә таянып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләрен (директорлар, балалар бакчалары мөдирләрен) аттестацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” 2017ел, 19 апрель, 3822/17 номерлы хаты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 ел, 13 июнь, 527 нче карары белән расланган Нурлат муниципаль районында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләрен (директорлар, балалар бакчасы мөдирләрен) аттестацияләү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктның өченче абзацың түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“База оешмалары җитәкчеләре өчен компьютер тестлаштыруы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегендә, аттестация үткәрү кысаларында, мәгариф бүлеге тарафыннан расланган материаллар буенча уздырыла”.

2. Кадрлар үзгәрүе сәбәпле, Нурлат муниципаль районында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешма җитәкчеләрен (директорлар, балалар бакчалары мөдирләрен) аттестацияләү буенча Нурлат муниципаль районы

Башкарма комитетының мәгариф бүлеге аттестация комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы “Мәгариф идарәсе” МКУ өлкән методисты Мартюшина Ольга Григорий кызын, эштән китү сәбәпле, аттестацияләү комиссиясе составыннан чыгарырга;

- аттестацияләү комиссиясе составына җаваплы сәркатип итеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы “Мәгариф идарәсе” МКУ аттестация һәм кадрлар белән эшләү буенча методисты Еремеева Галина Валентин кызын кертергә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин